РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Евлаштау, ул.Ш. Бариева, 23 тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш. Бариев урамы, 23 нче йорт тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.12.2023

КАРАР
№ 29

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 08.11.2021 ел, №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турындагы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы

КАРАР итә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел, №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба – положение тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны яна редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtau адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 29 нчы номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында 2нче Нигезләмә

## Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки бина хуҗалары булган оешмалардан алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай, квартал) мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы күпфатирлы йортта, күпфатирлы йорттагы биналардан файдаланучы гражданнар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат.

3. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

4. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылган очракта.

5. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган хезмәтләр, күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләр